**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5355**
**18.10.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче Карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру максатында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2019 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2019 елның 18 сентябрендәге 553/пр санлы Приказы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары белән расланган «2014-2022 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2019 елның дүртенче кварталына 53 024 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин